ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

***Постановление*** **Карар**

**17.01.2025** **г.Чистополь** **№ 9**

Чистай муниципаль районы
территориясендә хайваннарны
хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган
урыннар исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы "Чистай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы территориясендә хуҗалардан башка хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) бастырып чыгарырга.
4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының карары белән расланды
17.01.2025 ел, № 9

.

Чистай муниципаль районы территориясендә хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеге

1. Балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.
2. Иҗтимагый территорияләр (парклар, скверлар территорияләре, массакүләм ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).
3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.
4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.
5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына якын территорияләр, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары.
6. Йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар.
7. Күпфатирлы йортларга якын территорияләр, аларда урнашкан, мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән объектлар һәм бу территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юллары, моңа күпфатирлы йортларга якын территорияләргә юллар барлыкка китерүче автомобиль юллары да керә.
8. Зиратлар һәм мемориаль зоналар.